**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                                КАРАР

19.04.2024 ПР-70

Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибен расларга.
2. МКУ «Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы»на күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче                                                                                Р.А.Ильясов

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына ____________ 2024 ел, №_ кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында яшәгән гражданнарның түбәндәге категорияләрен җирләүгә бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү механизмын билгели (алга таба - хәрби хезмәткәрләр):

а) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

б) махсус операция уздыру зонасында Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар;

в) Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар,

г) махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар;

д) махсус операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре.

2. Җирләүне оештыру, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары (алга таба башкарма комитетлар) тарафыннан үлем турындагы документлар (үлем турында белешмә, үлем турында хәбәр, үлем турында таныклык) нигезендә башкарыла.

3. Һәлак булган хәрби хезмәткәрләрне җирләү Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары билгеләгән урыннарда, әгәр ихтыяри белдерүне үтәү мөмкин булмаган яисә Россия Федерациясе законнары белән башкача билгеләнмәгән шартлар килеп чыкмаса, вафат булганнан соң аның гәүдәсенә карата тиешле мөнәсәбәт турында ихтыяри белдерүенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

4. Үлгән кешенең ихтыяри белдерүе булмаса, аны җирләү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү хокукына тормыш иптәше, якын туганнары (балалар, ата - аналар, уллыкка алынганнар, уллыкка алучылар, туган абыйлары һәм туган апалары, оныклары, бабасы әбисе), башка туганнары ия.

5. Һәлак булган хәрби хезмәткәрне җирләүне оештыру Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына йөкләнә.

6. Ритуаль хезмәтләрнең түбәндәге төрләре түләнергә тиеш:

-һәлак булучының гәүдәсе белән табутны хушлашу (күмү) урынына алып бару;

- чардуган, венок, чәчәкләр китерү;

-почетлы каравыл, оркестр йөртү буенча транспорт хезмәтләре.

- ата-аналарга, тормыш иптәшенә яки балаларга бер тапкыр бирелә торган 30000 сум күләмендә матди ярдәм.

7. Ритуаль хезмәтләр өчен түләү Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан финанс документлары белән расланган чыгымнар буенча башкарыла (килешү, башкарылган эшләр акты, исәп-хисап, накладной, товар чегы).